**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ БОЕРЫК

20.09.2021 № 986

Нурлат муниципаль районында
Баланс комиссиясе төзү турында

Кулланучылар кооперациясен үстерү максатларында Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районында Баланс комиссиясен әлеге механизмга 1 нче кушымта нигезендә түбәндәге составта төзергә.
2. Нурлат муниципаль районында Баланс комиссиясе турында нигезләмәне әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 елның 20 сентябрендәге 986 номерлы карарына
1 нче кушымта

Нурлат муниципаль районында
Баланс комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Хәмзин<br>Рафис Рафик улы | - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Вилданов<br>Марсим Мөнип улы | - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы, комиссия рәисе урынбасары |
| Исхаков Ришат Әвкать улы | - авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы, комиссия секретаре |

<u>Комиссия әгъзалары</u>:

| | |
|---|---|
| 1. Маняпов Линар Нурислам улы | Нурлат муниципаль районы Башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| 2. Галәүтдинов Илнар Зөфәр улы | Җитештерү-маркетинг бүлеге консультанты (килешү буенча) |
| 3. Каняфина Венера Минсәлим кызы | Финанс -икътисад бүлеге консультанты (килешү буенча) |
| 4. Куклова Надежда Александровна | Финанс - икътисад бүлеге  башлыгы (килешү буенча) |

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 елның 20 сентябрендәге 986 номерлы карарына
2 нче кушымта

## Нурлат муниципаль районында Баланс комиссиясе турында нигезләмә

### I.Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә кулланучылар кооперациясен үстерү максатларында төзелгән Нурлат муниципаль районында Баланс комиссиясенең (алга таба - комиссия) эш тәртибен һәм вәкаләтләрен билгели.
2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, әлеге нигезләмәгә таяна.

### II. Комиссия вәкаләтләре

3. Комиссия кооперативлар белән идарә итүнең нәтиҗәлелеге турында кооператив рәисләренең хисапларын һәм докладларын тыңлый, аларны бәяли, аларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшли.

### III. Комиссиянең эш тәртибе

4. Комиссия Нурлат муниципаль районының территориаль органнары башкарма комитеты хезмәткәрләреннән төзелә һәм комиссия рәисеннән, комиссия әгъзаларыннан, комиссиянең җаваплы секретареннән тора.
5. Комиссия утырышлары рәис тарафыннан билгеләнә һәм кирәк булган саен уздырыла.
6. Комиссия утырышында комиссия әгъзалары кимендә ½ булса, ул тулы хокуклы дип санала.
7. Комиссия утырышын уздыру көне тәртибе, урыны, датасы һәм вакыты комиссия рәисе йә аны алмаштыручы зат тарафыннан билгеләнә.
8. Утырышны уздыру вакыты һәм көн тәртибе турында комиссия әгъзаларына аны үткәрүгә кадәр кимендә 5 эш көне алдан хәбәр ителә.
9. Комиссия утырышы беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссия рәисе һәм комиссиянең утырышта катнашучы барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.
10. Комиссия рәисе:
- комиссия эшчәнлеген оештыра һәм аңа җитәкчелек итә, аның утырышларында рәислек итә һәм комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәгән өчен шәхси җаваплылык йөртә;
- комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә;
- комиссия компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан үтәү мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирә һәм аларның үтәлешен тикшереп торуны оештыра.

12. Комиссия әгъзалары:
- комиссия утырышларында, комиссия компетенциясенә керә торган барлык мәсьәләләрне тикшерүдә һәм хәл итүдә катнашалар;

- комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча комиссия рәисенә мөрәҗәгать итәләр.

13. Комиссиянең җаваплы секретаре:

- комиссия утырышларын әзерләүне тәэмин итә;
- Утырышны уздыру вакыты һәм көн тәртибе турында тиешле хәбәрләр җибәрә, комиссия әгъзаларын чакыруны тәэмин итә;
- комиссия әгъзаларына аны үткәрү датасына кадәр кимендә 1 эш көне алдан комиссия утырышы өчен материаллар бирә;
- комиссия утырышлары беркетмәләрен һәм комиссия эшчәнлегенең башка материалларын рәсмиләштерә;
- комиссия әгъзаларын комиссия эшчәнлегенә бәйле материаллар белән таныштыра.